| УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ |
|---|---|---|
| **ПРИКАЗ**<br>05.10.2022 | Казан шәһәре | **БОЕРЫК**<br>№ 01-05/225 - пр |

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең 2018 елның 14 февралендәге 01-05/60-пр номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

БОЕРЫК БИРӘМ:

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең «Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмә раслау турында» 2018 елның 14 февралендәге 01-05/60-пр номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең 2022 елның 1 мартындагы 01-05/68-пр номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертеп, 16.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16.5. Әлеге Нигезләмәнең 15 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында аталган мөрәҗәгатьне яисә әлеге Нигезләмәнең 15 пунктының «б» пунктчасындагы бишенче абзацта һәм «д» пунктчасында аталган хәбәрләмәләрне карау нәтиҗәләре буенча нигезләнгән бәяләмәне әзерләгәндә Идарәнең оештыру-хокук эше бүлеге вазыйфаи затлары мөрәҗәгатьне яисә хәбәрләмәне тапшырган дәүләт хезмәткәре белән әңгәмә уздыру, аннан язмача аңлатмалар алу хокукына ия, ә Идарә башлыгы яисә аның махсус шуңа вәкаләтле урынбасары билгеләнгән

тәртиптә дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм мәнфәгатьле оешмаларга гарызнамәләр җибәрә, коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасыннан файдалана ала, шул исәптән гарызнамәләрне җибәрү өчен дә. Мөрәҗәгать яисә хәбәрләмә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар мөрәҗәгать яки хәбәрләмә килгән көннән соң җиде эш көне эчендә комиссия рәисенә тапшырыла. Гарызнамәләр җибәрелгән очракта мөрәҗәгать яисә хәбәрләмә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар комиссия рәисенә мөрәҗәгать яки хәбәрләмә килгән көннән соң 45 көн эчендә тапшырыла. Күрсәтелгән срок озайтылырга мөмкин, ләкин 30 көннән дә артыгракка түгел.».

Җитәкче вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы М.Ә.Халиков